КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 21 декабрь г.Казань № 1662

2024 елга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һәм Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрне һөнәри үстерү чараларына дәүләт заказы турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2024 елга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри үстерү чараларына дәүләт заказы структурасын, әлеге чараларны фәнни-методик, укыту-методик һәм мәгълүмати-аналитик тәэмин итүгә түләүләрне дә кертеп, финанслау күләме 13 250,2 мең сум белән;

2024 елга Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрне һөнәри үстерү чараларына дәүләт заказы структурасын, күрсәтелгән чараларны фәнни-методик, укыту-методик һәм мәгълүмати-аналитик тәэмин итүгә күчерүләрне дә кертеп, финанслау күләме 15 200,0 мең сум белән.

2. Татарстан Республикасы дәүләт органнары җитәкчеләренә һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һәм Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрне һөнәри үстерү чараларына расланган дәүләт заказы нигезендә җибәрүне тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 21 декабрь, 1662 нче
карары белән расланды

## 2024 елга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри үстерү чараларына дәүләт заказы структурасы

(кеше)

| Дәүләт органы исеме | Һөнәри үстерү чараларына җибәреләә торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре саны | | | |
|---|---|---|---|---|
| | барысы | шул исәптән | | |
| | | һөнәри яңадан әзерләү программалары буенча | квалификация күтәрү программалары буенча | һөнәри үстерүнең башка чаралары буенча |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе | 112 | | 40 | 72 |
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты | 63 | 1 | 24 | 38 |
| Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты | 75 | 1 | 34 | 40 |
| Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы | 15 | | 7 | 8 |
| Татарстан Республикасы Хисап палатасы аппараты | 19 | | 14 | 5 |
| Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппараты | 1 | | | 1 |
| Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппараты | 17 | 1 | 6 | 10 |
| Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе аппараты | 39 | | 32 | 7 |
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе | 17 | | 17 | |
| Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе | 57 | | 41 | 16 |
| Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция житештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе | 122 | | 70 | 52 |
| Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты | 4 | | 4 | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты | 13 | | 8 | 5 |
| Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты | 36 | 2 | 15 | 19 |
| Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты | 57 | | 30 | 27 |
| Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты | 24 | | 17 | 7 |
| Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеше күзәтчелеге инспекциясе | 60 | | 48 | 12 |
| Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты | 6 | | 6 | |
| Татарстан Республикасы Конституция советы | 9 | | 5 | 4 |
| Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы | 135 | 1 | 48 | 86 |
| Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | 55 | | 35 | 20 |
| Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы | 39 | | 30 | 9 |
| Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы | 25 | | 19 | 6 |
| Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | 100 | 1 | 60 | 39 |
| Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы | 32 | | 27 | 5 |
| Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы | 35 | | 17 | 18 |
| Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | 33 | 1 | 19 | 13 |
| Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | 271 | | 151 | 120 |
| Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы | 22 | | 10 | 12 |
| Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | 73 | 1 | 49 | 23 |
| Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы | 11 | | 4 | 7 |
| Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 118 | | 77 | 41 |
| Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы | 27 | | 15 | 12 |
| Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы (Татарстан Респуб- | 187 | | 119 | 68 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| ликасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты өчен) | | | | |
| Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы | 15 | 1 | 8 | 6 |
| Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министр-лыгы | 84 | 2 | 67 | 15 |
| Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | 78 | | 41 | 37 |
| Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы | 48 | | 22 | 26 |
| Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге Тулы вәкаләтле вәкиллеге | 10 | | 10 | |
| Татарстан Республикасының Әзәр-бәйҗан Республикасындагы тулы вәкаләтле вәкиллеге | 0 | | | |
| Татарстан Республикасының Төрек-мәнстандагы тулы вәкаләтле вәкиллеге | 0 | | | |
| Татарстан Республикасының Санкт-Петербург шәһәрендәге һәм Ленинград өлкәсендәге даими вәкиллеге | 3 | | 2 | 1 |
| Татарстан Республикасының Баш-кортостан Республикасындагы даими вәкиллеге | 0 | | | |
| Татарстан Республикасының Крым Республикасындагы һәм Севасто-поль шәһәрендәге даими вәкиллеге | 1 | | | 1 |
| Татарстан Республикасының Сверд-ловск өлкәсендәге даими вәкиллеге | 2 | | 2 | |
| Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы | 1 | | 1 | |
| Татарстан Республикасы Мини-стрлар Кабинетының Граждан хәле актларын теркәү идарәсе | 11 | | 5 | 6 |
| Татарстан Республикасының Үз-йөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек итү идарәсе | 24 | | 24 | |
| Барлыгы | 2 186 | 12 | 1 280 | 894 |

Искәрмә. 2024 елга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри үстерү чараларына дәүләт заказын финанслау күләмен исәпләгәндә дәүләт хезмәткәрләренең өстәмә санын, шулай ук дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган дәүләт органнарында вазыйфалар биләүче хезмәткәрләрне, шулай ук дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләрен (алга таба - башка

затларны) укыту мөмкинлеге каралган. Дәүләт хезмәткәрләренең һәм башка затларның өстәмә санын укытуга финанслау күләме 2 673,29 мең сумнан арта алмый.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 21 декабрь, 1662 нче
карары белән расланды

## 2024 елга Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрне һөнәри үстерү чараларына дәүләт заказы структурасы

(кеше)

| Муниципаль район исеме | Һөнәри үстерү чараларына җибәрелә торган Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләр саны | | | |
|---|---|---|---|---|
| | барысы | шул исәптән | | |
| | | һөнәри яңадан әзерләү программалары буенча | квалификация күтәрү программалары буенча | һөнәри үстерүнең башка чаралары буенча |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Әгерҗе муниципаль районы | 38 | 1 | 32 | 5 |
| Азнакай муниципаль районы | 51 | 1 | 45 | 5 |
| Аксубай муниципаль районы | 37 | | 20 | 17 |
| Актаныш муниципаль районы | 17 | | 14 | 3 |
| Алексеевск муниципаль районы | 12 | | 12 | |
| Әлки муниципаль районы | 17 | | 16 | 1 |
| Әлмәт муниципаль районы | 76 | | 62 | 14 |
| Апас муниципаль районы | 23 | | 20 | 3 |
| Арча муниципаль районы | 29 | | 27 | 2 |
| Әтнә муниципаль районы | 6 | | 6 | |
| Баулы муниципаль районы | 36 | | 27 | 9 |
| Балтач муниципаль районы | 23 | | 23 | |
| Бөгелмә муниципаль районы | 37 | | 36 | 1 |
| Буа муниципаль районы | 36 | | 32 | 4 |
| Югары Ослан муниципаль районы | 14 | | 13 | 1 |
| Биектау муниципаль районы | 40 | | 23 | 17 |
| Чүпрәле муниципаль районы | 23 | | 20 | 3 |
| Алабуга муниципаль районы | 25 | | 20 | 5 |
| Зәй муниципаль районы | 42 | | 36 | 6 |
| Зеленодольск муниципаль районы | 44 | | 39 | 5 |
| Кайбыч муниципаль районы | 17 | | 17 | |
| Кама Тамагы муниципаль районы | 20 | | 19 | 1 |
| Кукмара муниципаль районы | 36 | | 28 | 8 |
| Лаеш муниципаль районы | 32 | 1 | 27 | 4 |
| Лениногорск муниципаль районы | 49 | | 43 | 6 |
| Мамадыш муниципаль районы | 23 | 2 | 19 | 2 |
| Менделеевск муниципаль районы | 16 | | 12 | 4 |
| Минзәлә муниципаль районы | 22 | 1 | 14 | 7 |
| Мөслим муниципаль районы | 20 | | 19 | 1 |
| Түбән Кама муниципаль районы | 77 | 2 | 56 | 19 |
| Яңа Чишмә муниципаль районы | 17 | | 16 | 1 |
| Нурлат муниципаль районы | 48 | | 35 | 13 |
| Питрәч муниципаль районы | 20 | | 17 | 3 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| Балык Бистәсе муниципаль районы | 24 | | 21 | 3 |
| Саба муниципаль районы | 30 | | 23 | 7 |
| Сарман муниципаль районы | 35 | | 32 | 3 |
| Спас муниципаль районы | 17 | | 16 | 1 |
| Тәтеш муниципаль районы | 24 | | 16 | 8 |
| Тукай муниципаль районы | 41 | | 30 | 11 |
| Теләче муниципаль районы | 16 | | 16 | |
| Чирмешән муниципаль районы | 41 | 1 | 31 | 9 |
| Чистай муниципаль районы | 36 | | 33 | 3 |
| Ютазы муниципаль районы | 22 | | 17 | 5 |
| Яр Чаллы шәһәре | 193 | 1 | 136 | 56 |
| Казан шәһәре | 563 | 9 | 243 | 311 |
| Барлыгы | 2 065 | 19 | 1 459 | 587 |

Искәрмә. 2024 елга Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрне һөнәри үстерү чараларына дәүләт заказын финанслау күләмен исәпләгәндә муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче хезмәткәрләрнең, шулай ук муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең (алга таба – башка затлар) өстәмә санын укыту мөмкинлеге каралган. Муниципаль хезмәткәрләрнең һәм башка затларның өстәмә санын укытуга финанслау күләме 4 075,2 мең сумнан арта алмый.

---